ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора,
Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЕ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Кооперативная ур., 5, Биектау т/ю станциясепоселогы,
Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-50, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**15.11.2023** **№ 1755**

**«Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен эшләү турында**

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 31, 32 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 16 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14, 15 статьялары нигезендә, кызыксынган затларның мөрәҗәгатьләре нигезендә, Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләрен гамәлдәге законнар таләпләренә туры китерү зарурлыгына бәйле рәвештә, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мәмдәл авыл җирлеге» муниципаль берәмлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын эшләүгә керешергә.
2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ веб-адрес буенча һәм «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары Р.Ф. Хәкимуллинга йөкләргә.

Җитәкче Д.Ф. Шәйдуллин